**МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** | **БОЕРЫК**

26.12.2020 **Казан ш.** № 4184-р

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 16.11.2020, № 3495-р карары белән расланган 2021 елга салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясе Салым кодексының $378^{2}$ статьясының 7 пунктына, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының $1^{1}$ статьясына, “Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлеген булдыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында” 2014 елның 21 ноябрендәге № 896 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге № 977 карары белән расланган Салым салу максатларында биналарны (каралтыларны, корылмаларны) һәм йортларны фактта файдалану төрен билгеләү тәртибен һәм Салым салу максатларында биналарны (каралтыларны, корылмаларны) һәм йортларны фактта файдалану төрен билгеләү мәсьәләләрен карап тикшерү буенча комиссия турындагы нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.86 пунктына нигезләнеп:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 16.11.2020, № 3495-р (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 04.12.2020, № 3814-р карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

карары белән расланган 2021 елга салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлеген (алга таба – Исемлек) әлеге карарның кушымтасындагы 460 – 461 пунктлар белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

2. Күрсәтелгән үзгәреш исәпкә алынган Исемлекне электрон формада Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрендәге Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында бастырып чыгарырга:

4. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 26.12.2020 № 4184-р карарына кушымта

| 2021 елга салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлеге<br>(үзләренә карата кадастр бәясе салым бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелгән биналарда (каралты, корылма) урнашкан бүлмәләр.) | | | |
|---|---|---|---|
| **№** | **Бинаның кадастр номеры (корылма, каралты)** | **Бүлмәнең кадастр номеры** | **Күчемсез милек объектының адресы** |
| 460 | 16:52:050305:2744 | | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 40А |
| 461 | 16:52:050305:2784 | | Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Сөембикә проспекты, 40В |